ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗУР КУККУЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2025 ел, 9 апрель N 155

Зур Куккуз авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Куккуз авыл җирлегенең Советы карар чыгарды:

1. "Зур Куккуз авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Куккуз авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 апрелендәге 31 номерлы карары белән расланган Зур Куккуз авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.1.гражданның мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка «Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба - Бердәм портал), дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының бүтән мәгълүмат системасыннан йә җирле үзидарә органының рәсми сайтыннан гражданнарның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итә торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (әгәр «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса), тәкъдим яисә шикаять яисә гражданның җирле үзидарә органыннан телдән мөрәҗәгать итүе;»;

3.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3.7.Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысын) мәҗбүри рәвештә күрсәтә, шулай ук электрон почта адресын күрсәтә йә Бердәм порталда яисә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасында җаваплар җибәрелергә тиешле гражданның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итә торган шәхси кабинетның адресын (уникаль идентификаторын) файдалана. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә кушып бирергә хокуклы.»;

4.15 пунктта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Мөрәҗәгатькә җавап җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә килгән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча йә Бердәм порталда яисә җирле үзидарә органына яисә җирле үзидарә органына язма формада кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон документ рәвешендә юллана."

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга. 3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районының
Зур авыл җирлеге башлыгы урынбасары,
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районының
Зур Куккуз авыл җирлеге Советы Рәисе А.Г.Ибрагимов